| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**11.04.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 78** |

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлардан кергән, вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамәләрне карау буенча вәкаләтле комиссия тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган затлар тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча вәкаләтле комиссияне билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2016 елның 11 апрелендәге
78 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы»**
**муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар**
**биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр**
**конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган**
**шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрергә тиеш.

Хәбәр язма рәвештә вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр рәвешендә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

3. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче түбәндәге затларга кагыла: Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе (алга таба - муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар).

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә (алга таба - Комиссия) әлеге Нигезләмәгә кушымта формасы нигезендә төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлардан, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

5. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына тапшырыла, ул Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә уздырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык булырга тиеш түгел.

6. Комиссия хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарларны муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә кабул итә.

7. Хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булмавын таныырга;

б) муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерә ала дип танырга;

в) муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

8. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «б», «в» пунктчаларында каралган карарлар кабул иткән очракта, Комиссия карары һәм аңа кушып бирелгән документлар Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрелә һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының алдагы утырышында каралырга тиеш.

9. Зеленодольск муниципаль районы Советы килгән Комиссия карарын карый һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының законнары һәм муниципаль хокукый актлары нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрү турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында нигезләмәгә карата кушымта

______________________________
(танышу турында билге)

______________________________________
Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә

______________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа)

вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга) .

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ______________________________________________________________
___________________________________________________________________________________

Гамәлгә ашырылуына шәхси кызыксыну йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вәкаләтләр: __________________________________________________
___________________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________

Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмимим) (тиешле фикерен ассызыкларга).

"____"________________ 20__________________________ ______________________
(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаны расшифровкалау)